ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 г.Лениногорск № 87

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәр Советының 2017 елның 08 августындагы 111 номерлы карары белән расланган контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон (2021елның 30 декабрендәге редакциядә), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2022 елның 7 мартындагы 02-08-03 номерлы протестын карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәр Советының 2017 елның 08 августындагы 111 номерлы карары белән расланган контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның «г» пунктчасында «акцияләр (оешмаларның устав (җыю) капиталларында пайларның катнашу өлеше)» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор –«Лениногорские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов